РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТУЕМБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУЕМБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422114, Республика Татарстан, Кукморский район,
с. Туембаш, ул. Ленина, д.68
тел.: 8(84364) 31-5-44
эл. почта: Tuem.Kuk@tatar.ru

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Туембаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР**

«15» апрель 2025 ел. № 10

Туембаш авыл җирлеге Советының 2024 елның 11 июнендәге 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Туембаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Туембаш авыл җирлеге Советының 2024 елның 11 июнендәге 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4 бүлектәге 4.23 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) контроль чара, шулай ук Контроль төре турында Федераль законда каралган башка чаралар акты рәсмиләштерелгәннән соң, контрольдә тотылучы затка ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында, аларны бетерүнең уңайлы вакытын күрсәтеп, күрсәтмә бирергә, шулай ук Контроль төре турындагы Федераль законда каралган башка чараларны күрсәтеп, күрсәтмә бирергә;».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Туембаш авыл җирлеге башлыгы И.Ф. Гарипов